КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 июнь г.Казань № 444

2020 елда «Татарстан Республикасында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру» дәүләт программасын гамәлгә ашыру барышы һәм 2021 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә дәүләт сәясәтен алга таба тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын 2020 елда тормышка ашыру барышы һәм 2021 елга бурычлар турында» хисабын хупларга.

2. Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге һәм экология буенча Татарстан халыкара форумы исемен Энергетика һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумына үзгәртергә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына хисап кварталыннан соң килә торган айның 25енә кадәр бюджет өлкәсендәге республика оешмаларының энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре буенча мәгълүматны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына квартал саен кертүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына:

2021 елның 1 августыннан 1 ноябренә кадәр Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Энергетика ресурсларын куллану турында декларация бирү тәртибен һәм энергетика ресурсларын куллану турында декларация формасын раслау

хакында» 2019 елның 28 октябрендәге 707 номерлы боерыгы белән расланган формалар буенча 2020 ел өчен энергетика декларацияләрен, шул исәптән ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре (булганда) буенча бирүне тәэмин итәргә.

2021 елның 1 октябренә кадәр ресурсларны куллануны киметүнең максатчан дәрәҗәсенә ирешүен тәэмин итү өчен энергия сервисы контрактын төзергә кирәк булган ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре (булганда) исемлеген төзергә;

2021 елның 1 декабренә кадәр ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре (булганда) өчен 2021 – 2023 еллар чорына алар куллана торган дизель һәм башка ягулык, мазут, табигый газ, җылылык энергиясе, электр энергиясе, күмернең суммар күләмен, шулай ук алар куллана торган су күләмен чагыштырма шартларда киметүнең максатчан дәрәҗәсе белән билгеләнгән нигездә (алга таба – ресурслар куллануны киметүнең максатчан дәрәҗәсе) энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча элек расланган программаларны эшләүне яисә корректировкалауны тәэмин итәргә;

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

хисап кварталыннан соң килә торган айның 25енә кадәр ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрнең энергия нәтиҗәлелеге күрсәткечләре буенча мәгълүматны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына квартал саен бирүне тәэмин итүне;

2021 елның 1 августыннан 1 ноябренә кадәр Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Энергетика ресурсларын куллану турында декларация бирү тәртибен һәм энергетика ресурсларын куллану турында декларация формасын раслау хакында» 2019 елның 28 октябрендәге 707 номерлы боерыгы белән расланган формалар буенча 2020 ел өчен энергетика декларацияләрен, шул исәптән ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләре (булганда) буенча бирүне тәэмин итәргә;

2021 елның 1 октябренә кадәр ресурсларны куллануны киметүнең максатчан дәрәҗәсенә ирешүен тәэмин итү өчен энергия сервисы контрактын төзергә кирәк булган ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләре исемлеген төзергә;

2021 елның 1 декабренә кадәр, ресурсларны куллануның билгеләнгән максатчан дәрәҗәсе нигезендә, энергияне сак тоту һәм ведомство буйсынуындагы муниципаль учреждениеләрнең энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча элек расланган программаларны эшләүне яисә корректировкалауны тәэмин итәргә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә ресурсларны куллану киметүнең максатчан дәрәҗәсен исәпләгәндә, шулай ук энергия сервисы контрактлары төзү юлы белән энергия саклау чараларын әзерләгәндә һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә методик һәм консультация ярдәме күрсәтергә.

7. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары

белән берлектә, энергетика нәтиҗәлелеге һәм энергетиканы үстерү буенча «Россия энергетика атнасы» халыкара форумында һәм #ВместеЯрче бөтенроссия энергетика саклау һәм экология фестивалендә Татарстан Республикасының катнашу мөмкинлеген эшләргә.

8. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына энергетика нәтиҗәлелеге һәм энергетиканы үстерү буенча «Россия энергетика атнасы» халыкара форумында һәм #ВместеЯрче бөтенроссия энергетика саклау һәм экология фестивалендә Татарстан Республикасы катнашуын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү» дәүләт программасын 2018 елда тормышка ашыру барышы һәм 2019 елга бурычлар турында» 2020 ел, 29 сентябрь, 882 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

10. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры А.Ә. Кәримовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин